КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 октябрь г.Казань № 911

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2017 ел, 20 март, 155 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибен билгеләү турында» 2017 ел, 20 март, 155 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 май, 584 нче карарына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын әзерләү һәм раслау тәртибен, мондый планнарга карата таләпләрне, җирле үзидарә органнары һәм махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан мондый планнарны әзерләү, аларга үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын әзерләү һәм раслау тәртибен, мондый планнарга карата таләпләрне,

җирле үзидарә органнары һәм махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан мондый планнарны әзерләү, аларга үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын раслау тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планнарын әзерләү һәм раслау тәртибе, мондый планнарга карата таләпләр, җирле үзидарә органнары һәм махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан мондый планнарны әзерләү, аларга үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне бирү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы $7^2$ өлеше, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясындагы $3^1$ өлеше нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын (алга таба – Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планы) һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планнарын (алга таба – Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы муниципаль планнары) әзерләүгә һәм раслауга карата таләпләр билгели, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан мондый планнарны әзерләү, аларга үзгәрешләр кертү өчен кирәкле белешмәләрне бирү тәртибен билгели.»;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

«$8^1$. Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын гамәлгә ашыра башлаган елга кадәрге елның 1 сентябренә кадәр махсус счетта капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре, әгәр мондый күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү Россия Федерациясе Торак кодексының 167 статьясындагы 2 өлеше нигезендә үткәрелгән булса, җирле үзидарә органына күпфатирлы йортларның техник торышын тикшерү нәтиҗәләрен тапшыра.»;

14 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына үзгәрешләр түбәндәге нигезләр буенча елга кимендә бер тапкыр кертелә:»;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) күпфатирлы йортның техник торышын тикшерү нәтиҗәләре буенча Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планында каралган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яисә) эшләр башкару билгеләнгән срокта таләп ителми.»;

15 пунктта «9» санын «10» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 15[1] пункт өстәргә:

«15[1]. Әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән белешмәләр махсус счетта күпфатирлы йорттагы капиталь ремонт фондын формалаштыручы күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан җирле үзидарә органына Программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын гамәлгә ашыру елына кадәрге елның 1 июленә кадәр тапшырыла.»;

17 пунктта «капиталь ремонт ясау буенча дәүләт программасын» сүзләрен «күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасын» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин